ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
11.12.2025

Иннополис шәһәре

КАРАР
100

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең торак комиссиясен төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары, «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган,Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә социаль ипотека программасын гамәлгә ашыру максатларында, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге торак комиссиясен, әлеге карарның 1 нче кушымтасына ярашлы составта булдырырга.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге торак комиссиясе турында Нигезләмәне, әлеге карарның 2 нче кушымтасына ярашлы рәвештә расларга.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырылган көннән үз көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан мәгълүмат стендында игълан ителергә тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Я.Н. Елистратовка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы И.Ф. Ханбиков

Иннополис шәһәре комитетының
2025 елның «11» декабреннән
№ 100 карарына
1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге торак комиссиясе составы

Комиссия рәисе

| | | |
|---|---|---|
| Ханбиков Илгиз Фәрит улы | - | Иннополис шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |

Комиссия рәисе урынбасары

| | | |
|---|---|---|
| Елистратов Ярослав Николаевич | - | Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |

Комиссия секретаре

| | | |
|---|---|---|
| Салихова Алена Олеговна | - | Иннополис шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеген эксплуатацияләү буенча баш белгеч |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Астраханцева Светлана Витальевна | - | Иннополис шәһәре Башкарма комитетының финанс бүлеге җитәкчесе; |
| Рәхмәтов Булат Рафаэл улы | - | Иннополис шәһәре Башкарма комитетының хокукый ярдәм бүлеге башлыгы; |
| Хөснетдинова Альбина  Вакиф кызы | - | МКУ «Иннополис шәһәре башкарма комитеты» беренчел Профсоюз оешмасы рәисе; |
| Хәбибуллин Айрат Рәшатович | - | «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» АНО директоры (килешү буенча); |
| Александрова Ольга Николаевна | - | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» АҖ генераль директорының корпоратив идарә буенча урынбасары (килешү буенча); |
| Закирова Регина Александровна | - | «Иннополис Сити» АҖ генераль директорының персонал буенча урынбасары (килешү буенча); |
| Вәлиев Радик Фларитович | - | «Иннополис Университеты» югары белем бирү оешмасының үсеш һәм кадрлар сәясәте буенча директоры (килешү буенча). |

Иннополис шәһәре комитетының
2025 елның «11» декабреннән
№ 100 карарына
2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» унципаль берәмлегенең торак комиссиясе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» унципаль берәмлегенең торак комиссиясе (алга таба – Комиссия) дәүләт һәм муниципаль милектә булган торак мәйданын дөрес исәпкә алу, бүлү, гражданнарның торакка хокукларын гамәлгә ашыру шартларын булдыру, торакны ирекле рәвештә югалтуга юл куймау, торак биналар белән идарә итү, файдалану һәм аларны бүлү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның тигезлеген тану, бозылган торак хокукларын торгызу функцияләрен башкара.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, башка норматив һәм хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.3. Комиссия составы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм торак комиссиясе әгъзаларыннан тора.

2. Торак комиссиясенең төп бурычлары

2.1. Торак комиссиясенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу турында гражданнарның гаризаларын карау;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге № 190 карарына ярашлы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибе турында карар кабул итү өчен кирәкле гаризага кушылган анкета һәм документлар исемлегенең тулы булуын тикшерү;

- социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләрне исәпкә алу һәм исәпкә куюдан баш тарту турында тәкъдимнәр әзерләү;

- гамәлдәге законнар нигезендә махсуслаштырылган оешмаларга тәкъдим ителә торган социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга гариза бирүчеләр реестрын килештерү;

- законнар нигезендә социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алынган гаиләләрнең исәпкә алу эшләрен, реестрны төзүнең һәм алып баруның дөреслеген һәм локаль исемлекләрен саклауны тикшереп тору.

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган квоталарга туры китереп, социаль ипотека буенча төзелгән торак биналарны бүлү өчен Башкарма комитет тарафыннан тәкъдим ителгән гаиләләр исемлеген килештерү.

## 3. Торак комиссиясе составы

3.1. Торак комиссиясе составына җирле үзидарә органнары, хезмәт коллективлары, профсоюзлар, шәһәр төзүче, белем бирү һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә.

Торак комиссиясе түбәндәге әгъзалардан торырга тиеш:

1) торак комиссиясе рәисе - җирле үзидарә органы җитәкчесе;

2) торак комиссиясе рәисе урынбасары - җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары яки җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән билгеләнгән вазифаи зат;

3) комиссия секретаре - җирле үзидарә органы тарафыннан гаиләләрне исәпкә алу һәм социаль ипотека буенча торак биналар сатып алу өчен исәптә торучы гаиләләр реестрын алып бару өчен вәкаләтле вазифаи зат;

4) комиссия әгъзалары:

- җирле үзидарә органы вазифаи затлары;
- хезмәт коллективлары, профсоюз оешмалары вәкиле;
- шәһәр төзүче оешмалар вәкилләре.

Торак комиссиясен рәис җитәкли. Торак комиссиясе рәисе булмаганда, аның бурычлары комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

Кворум өчен торак комиссиясе составында әгъзаларның саны так санлы булмаса да, кимендә 7 кеше булырга тиеш.

## 4. Торак комиссиясе эшчәнлеген оештыру

4.1. Торак комиссиясе рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

4.2. Торак комиссиясе утырышлары расланган план нигезендә, әмма айга бер тапкырдан да ким булмаганча үткәрелә. Утырышлар, әгәр анда торак комиссиясе әгъзаларының 50% тан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия сәркатибе гражданнарны исәпкә алу мәсьәләсен карау өчен барлык кирәкле документларны әзерли.

4.4. Торак комиссиясе утырышында гражданнарны социаль ипотека буенча торак алу өчен исәпкә алу (исәпкә алудан баш тарту) мәсьәләләре протокол белән рәсмиләштерелә.

4.5. Әгәр утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелеге аның өчен тавыш бирсә, торак комиссиясе карары кабул ителгән дип санала. Торак комиссиясе карары киңәш характерына ия.

4.6. Торак комиссиясе карарын исәпкә алып, Башкарма комитет җитәкчесе гражданнарны социаль ипотека буенча торак алу өчен исәпкә алу турында күрсәтмә чыгара.

4.7. Торак комиссиясе секретаре социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләрнең реестрын формалаштыра, аны Башкарма комитет җитәкчесе белән раслый һәм махсуслаштырылган оешмага (Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды) законнар нигезендә тапшыра.

4.8. Торак комиссиясе социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алынган гаиләләрнең локаль исемлекләрен формалаштыру, алып бару, аларның дөреслеген контрольдә тоту эшендә катнаша.

4.9. Торак комиссиясе социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен гариза биргән гариза бирүчеләрне яңадан теркәүдә катнаша.

## 5. Торак комиссиясенең җаваплылыгы

Торак комиссиясе әгъзалары гамәлдәге законнар нигезендә социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен реестрны формалаштыру, исәп эшләрен алып бару һәм гаиләләрнең локаль исемлекләрен саклау өчен җаваплы.